ГЛАВА НИЖНЕСУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

Карар
" 22" ноябрь 2019 ел

Постановление
№ 5

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең Колышчы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге муниципаль берәмлеге" Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Колышчы авылы , Аркадий Гайдар урамы 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында 2019 елның 22 ноябрендә сәгать 11.00 дә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең Колышчы авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегенең Колышчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Колышчы авылы торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау ( материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү).;
- Колышчы авылы торак пунктында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү).;
- Колышчы авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.
- Колышчы авылы торак пунктында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру;;

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитетына Колышчы авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге башлыгы: Р.Ш.Гафиятуллин